КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 август г.Казань № 665

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ведомствосында булган аерым нетиповых оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең бу карарның 1 нче пункты нигезендә билгеләнә торган эш хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи йөкләмәләре күләмен саклау һәм алар шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты белән, бу карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкәндә гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнелә торган эш хакыннан азрак була алмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым нетиповых оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле һөнәр ияләре берлекләре органы белән килештереп:

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокук актларына тиешле үзгәрешләр кертергә;

Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым нетиповых оешмалары хезмәткәрләренә бу карар белән билгеләнгән хезмәт өчен түләү системасын керткәнгә кадәр, ике айдан да соңга калмыйча, хезмәтнең төп шартларына үзгәрешләр кертү турында хәбәр итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләре өчен 2018 елның 1 ноябреннән хезмәт өчен түләү шартларын билгеләү буенча шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

5. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карарның 1 пункты 2018 елның 1 ноябреннән үз көченә керә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче; 2015 ел, 20 февраль, 104 нче; 2015 ел, 10 март, 140 нчы; 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы; 2015 ел, 16 май, 350 нче; 2015 ел, 14 август, 591 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 889 нчы; 2015 ел, 30 декабрь, 1031 нче; 2016 ел, 26 гыйнвар, 38 нче; 2016 ел, 13 май, 314 нче; 2016 ел, 20 июль, 491 нче; 2016 ел, 30 сентябрь, 698 нче; 2017 ел, 16 март, 146 нчы; 2017 ел, 13 июнь, 382 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 735 нче; 2018 ел, 31 май, 412 нче; 2018 ел, 4 июнь, 418 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гамәле 2018 елның 1 ноябреннән Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмаларына һәм Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым нетиповых оешмаларына кагылмый.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин